| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ<br>КОМИТЕТ АЛЬКЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | Базарлы Матак авылы | **КАРАР** |
|---|---|---|

2014 елның 21гыйнвары 19№

**"Әлки муниципаль районы“ муниципаль берәмлегенең мәктәпкәчә белем бирү оешмасы эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау” турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 1013 елның 30 декабрендәге “Татарстан Республикасының мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында" 1096 ннмерлы карары нигезендә, Әлки муниципаль районында мәктәпкәчә мәгариф оешмаларын булдыруның нәтиҗәлелеген арттыру, мәктәпкәчә белем бирүнең бюджет белем бирү хезмәтләренең сыйфатын күтәрү максатларында Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Кушымталарны расларга:

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә финанс чыгымнары нормативларын исәпләү буенча методик тәкъдимнәр;

Әлки муниципаль районының мәктәпкәчә мәгариф оешмаларын финанс белән тәэмин итү күләмен исәпләү тәртибе;

Әлки муниципаль районының мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында мөлкәтне тотуга, коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә чыгымнарга, элемтә хезмәтләренә норматив чыгымнарны, бассейннарны тотуга норматив чыгымнарны исәпләү тәртибе;

Әлки муниципаль районының мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә норматив финанс чыгымнарын исәпләү тәртибе;

Әлки муниципаль районының мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында тәрбияләнүчеләрне карау һәм тәрбияләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны исәпләү тәртибе;

Әлки муниципаль районының мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында балаларны  карау һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвен формалаштыру һәм алу тәртибе;

2. Әлки муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына (Габыйдуллин И.И.) һәм Әлки муниципаль районы  Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенә тәэмин итәргә:

Мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләрен финанслау нормативларын формалаштырганда кулланыла торган  һәм финанс белән тәэмин итү исәбендә кулланылучы  "Әлки муниципаль районы"  муниципаль берәмлегенең мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре характеристикаларына мониторинг алып бару;

Һәр елны Әлки муниципаль районы бюджетын кабул иткәнчегә кадәр әлеге карарның пунктта расланган Тәртипләре нигезендә исәп-хисап ясау;

Әлки муниципаль районының мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында тәрбияләнүчеләрне карау һәм тәрбияләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны исәпләү;

Әлки муниципаль районының мәктәпкәчә мәгариф оешмаларын финанс белән тәэмин итү күләме нормативын;

Әлки муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында балаларны тәрбияләгән һәм караган өчен ата-аналар түләвен формалаштыру һәм алу.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары М.А. Платоновага  йөкләргә.

4. Әлки муниципаль районы  Башкарма комитетының 2008 елның 5 маендагы "Әлки муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең мәктәпкәчә белем бирү оешмасы эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында" 145 номерлы карарын 2014 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалткан дип санарга.

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе                                        А.Ф.Никошин